3. Мөхәммәдьяр. Нуры содур. Поэмалар, шигырь. – Казан: Татарстан китап нәшр., 1997. – 336 б.
4. Рахимова А.Р. Семантические особенности арабских и персидских заимствований в турецком и татарском языках // Востоковедение. Сборник статей и докладов. Выпуск II, III / Отв. ред. Г.Г. Зайнуллин. – Казань: Казанский госуниверситет, 2005. – С. 124-136.

**Салахутдинова Зифа Фаниловна,**

**Миргалимова Зиля Фаниловна,**

*к. филол. н., доценты кафедры*
*татарского языка и литературы,*
*методики их преподавания НГПУ*
*г. Набережные Челны, Татарстан, Россия*
*e-mail: sal-zifa@yandex.ru; zilia64@mail.ru*

УДК 81’373’2

# ФОАТ САДРИЕВНЫҢ “БӘХЕТСЕЗЛӘР БӘХЕТЕ” РОМАН-ТРИЛОГИЯСЕНДӘ КУШАМАТЛАР

# ИМЕНА-ПРОЗВИЩА В РОМАНЕ-ТРИЛОГИИ “СЧАСТЬЕ НЕСЧАСТНЫХ” ФОАТА САДРИЕВА

# NAMES-NICKNAMES IN THE NOVEL-TRILOGY “UNHAPPY HAPPINESS” THE FOATA SADRIYEV

**Аннотация.** Исследованы имена-прозвища, использованные в романе-трилогии “Счастье несчастных” Фоата Садриева. Освещены особенности функционирования этих поэтических антропонимов в художественном мире писателя как идиостилевых черт. Проведен частичный лингвистический анализ и интерпретация рассмотренных языковых единиц.

**Ключевые слова:** личное имя-прозвище, поэтические антропонимы, художественный мир писателя, интерпретация языковых единиц.

**Abstract.** Researched the nicknames used in the novel-trilogy “unhappy Happiness” the Foata Sadriyev. The peculiarities of functioning of these poetic personal names in the artistic world of the writer as idiostyle hell. A partial linguistic analysis and interpretation are considered linguistic units.

**Keywords:** personal name-nickname, poetic anthroponyms, artistic world of the writer, interpretation of language units.

Фоат Садриев – татар прозасының поэтик лингвистикасын үстерүдә матур үрнәкләр барлыкка китерүче талант иясе. Кешеләр һәм предметларны тасвирлауда гадилек, кыскалык, дөреслек; тел чаралары сайлауда һәм куллануда кыюлык һәм оригинальлек; тирән лирика, психологизм, фразаның матурлыгы һәм музыкальлеге – болар һәммәсе дә Ф.Садриевның телгә булган таләпләре. Шуның өстенә, Ф.Садриев үз әсәрләрен геройларына кушаматлар тагу белән баеткан. Билгеле, татар авылы (ә язучының персонажлары, нигездә, авыл кешеләре) кушаматларга бай була. Бу язучының “Бәхетсезләр бәхете” әсәрендә дә яктыртылмыйча калмаган. Роман-трилогиядә шактый гына кызыклы кушаматлар бар.

Кушамат – ике сүз кушылу юлы белән ясалган кушама (“кушма”) + ат (“исем”). Кешенең рәсми исеменә кушым, өстәмә ат (исем) дигән мәгънә белдерә [3, б. 224]. Татар авылында кушамат барлыкка килүдә төп рольне ике фактор уйный. Беренче һәм төп фактор – кеше үзе, аның күзгә бәрелеп торырлык индивидуаль сыйфатлары яки аның белән бәйле берәр очрак. Икенчесе – тирә-юньдәгеләрнең бу кешегә мөнәсәбәте, кушамат бирүче теге яки бу кешенең аерым сыйфатларын күреп ала һәм аны туры яки кыек итеп әйтеп бирә *(*Тискәре кәҗә, Төрмә кошы, Аксак шайтан һ.б.ш. – “Бәхетсезләр бәхете” әсәреннән).

1) Теләсә нинди әдәби сүз кебек, матур әдәбият әсәрләрендәге кушаматлар да тормыш-көнкүрешнең төрле күренешләрен чагылдыру белән бергә, атау функциясен генә үтәп калмыйлар, ә характерлаучы чара буларак та кулланылалар. Поэтик антропонимнарның бу категориясе экспрессия көченең иң мөһим сурәтләү чарасы булып тора, хикәяләүне милли колорит белән баета.

1) Матур әдәбият әсәрендә язучы кушаматларны үзенчәлекле метафоралар буларак та куллана. Билгеле булганча, матур әдәбият әсәре, көндәлек тормышны яктырту белән бергә, эстетик функцияләрне дә

үти. Бу авторның үз персонажына нинди кушамат бирүеннән дә күренә. Аларның күбесе тарихи, метафорик һәм семантик яктан мотивлаштыру белән аерыла, җөмләләрнең образлы-поэтикасын формалаштыруда да мөһим роль уйный.

Кушаматлар кешегә төрле тормыш ситуацияләреннән, таныш әдәби әсәрләрдән, тормыш һәм эш шартларыннан чыгып кушыла. Вакыт үтү белән алар онытылырга мөмкин, яңа вариантлары барлыкка килергә яки яңа кушаматлар белән алмашынырга мөмкин. Кешенең хәтта параллель рәвештә берничә кушаматы да булырга мөмкин.

"Бәхетсезләр бәхете" роман-трилогиясендә Фоат Садриев тарафыннан геройларга кушамат бирүнең төп алты мотивын күрсәтергә мөмкин.

1) Кешенең физик кимчелегенә бәйле, яки тышкы билгеләрне күрсәтүче кушаматлар. Алар теге яки бу геройга характеристика бирергә ярдәм итәләр: Аксак шайтан һ.б.ш. Аксак шайтан – кешеләрне гел борчып, начарлыкка гына алып баручы яхшылык эшли белмәүче герой: Көне-төне титаклап чапты Гайсә, беркемгә дә тынгы бирмәде. "Аксак шайтан" дигән кушамат тагылды, мулла кушкан исеме онытылды [1, б. 82].

2) Кешенең эшчәнлеге, һөнәре белән бәйле кушаматлар: Гармунчы Сирай, Лесник Талип һ.б.ш. Гармунчы Сирай – кечкенәдән үк гармунда уйнарга яратучы, җыр-моңга бик әвәс булган, яшьлеген дә чордашлары белән гармунда уйнап, яшьтәшләрен җырлатып уздырган герой: – Яшь чакта без сайрамаган сандугачны сайрата идек. Минем исем гармунчы Сирай булды [1, б. 183].

Лесник Талип – урманчылык белән шөгыльләнгән, табигатьне бик яраткан герой. Һәрбер хайван-җәнлекне, үсемлекне күңеле белән тоеп, алар өчен җанын бирергә әзер булганлыктан әлеге кушамат бирелгән: – Лесник Талип. Ул аннан как раз такталык нарат сорап йөри иде [1, б. 92].

3) Кешенең эш урыны белән бәйле кушаматлар: Р*айком күсесе* һ.б.ш.

Райком күсесе – райком эшчесе; күпсанлы халыкка ярый белгәнгә, шул урында озак еллар эшләгән герой: Мәлс абыйсы, райкомда яки урамда аны очратса, "нихәл, райком күсесе" дип кул бирде [1, б. 41].

4) Кешенең физик, физиологик, рухи һәм акыл үзенчәлекләрен күрсәтүче кушаматлар: Әпчүк, Тискәре кәҗә һ.б.ш. Тискәре кәҗә – кушканны үтәргә яратмаучы, буйсына белмәүче, бер кешегә дә "ярар" дип әйтмәүче герой: Кушканны үтәү, кемнеңдер әйдәкләвенә буйсыну – бала чактан ук аның өчен үлем белән бер иде. Шуңа күрә өйдә дә, мәктәптә дә, урамда да аның кушаматы "тискәре кәҗә" булды [1, б. 73].

Әпчүк – аны берничек тә җиңә алмаганнар, бик әрсез булганга күрә шундый кушамат бирелгән герой: Гел төшеп торучы замана кыраулары суга алмаганга, аңа Әпчүк (ач солы, солыча, әрсез чүп үләне) кушаматы такканнар. Аулак урыннарда Әпчүкне телләре тузганчы мунчала урынына чәйниләр иде [1, б. 89].

5) Хайваннар дөньясы белән бәйле кушамат: Фауна һ.б.ш. Фауна – фамилиясе Арсланов булганга бирелгән. Билгеле булганча, Арыслан – кыргый хайваннарның бер төре, димәк, фауна белән бәйле: Кайсыдыр йомры башы Арслановка да "Фауна" дигән кушаматны китереп чәпегән [1, б. 89].

6) Кеше тормышында нинди дә булса (яисә бер генә) очрак белән бәйле кушаматлар. Мондый кушаматлар читтән караганда гадәти булмаган, тормыш, яшәеш кануннарына туры килмәгән хәлгә ишарә ясыйлар. Кайвакыт шушы вакыйга булган урын исеме дә кушамат кушуга сәбәп була ала. Төрмә кошы – тормыш-яшәеш кануннарын бозып, тәртипсез яшәү рәвеше алып барган, ирекле тормыштан мәхрүм ителгән, гел төрмәдән кайтып кермәгән герой: – *Теге көнне* "төрмә кошы" дигән идем, кыйнады [1, б. 511].

Язучы әсәрендәге кушаматларның семантикасына килгәндә, Ф.Садриев романында очраган кушаматларны функциональ-семантик нигездә *ике* төркемгә бүлеп карарга мөмкин: 1) бәя бирүче кушаматлар: Тискәре кәҗә, Фауна, Төрмә кошы, Аксак шайтан, Әпчүк; 2) сурәтләүче кушаматлар. Болары кешенең тышкы кыяфәтен, темпераментын, эш һәм яшәү урынын күрсәтүчеләр: Аксак шайтан, Лесник Талип, Гармунчы Сирай, Райком күсесе һ.б.ш.

Кешене реаль характерлаучы кушаматларны туры мәгънәле кушаматлар дип атарга мөмкин. Барлык сурәтләүче кушаматлар да туры кушаматлар була.

Кушаматларның күчерелмә мәгънәсе ниндидер охшашлык, тере һәм тере булмаган күренешләр һәм кеше арасындагы эчке һәм тышкы бәйләнешләр нигезендә барлыкка киләләр. Ф.Садриев әсәрендә күчерелмә мәгънәдә кулланылган кушаматларны түбәндәге төрләргә бүлеп карарга була: 1) метафорик кушаматлар: Тискәре кәҗә, Төрмә кошы, Аксак шайтан, Әпчүк; 2) метонимик кушаматлар: Фауна, Төрмә кошы; 3) синекдохик кушаматлар. Мондый кушаматлар кешенең киеме яки тән өлешләренең атамаларын ялгызлык исемнәре белән алмаштырылганда барлыкка килә. Чөнки кеше тәненең бер өлеше яки аның киеме аталганда, ул үзе тулысынча күздә тотыла. Мәсәлән: Аксак шайтан. Бу очракта аксак аяк аша кеше үзе тулысынча күздә тотыла. Ә өстәвенә аның шайтанга да охшатылуы исә бу лексик берәмлекнең шул ук вакытта метафора да булып килүен күрсәтә. Тикшеренүләребездән күренгәнчә, романда күчерелмә мәгънәдә кулланылган кушаматларның кайберләре икешәр төркемгә дә керергә мөмкин (Аксак шайтан, Төрмә кошы).

Лексик-грамматик яктан кушаматлар, нигездә, исем сүз төркеменә керәләр. Исемнәр, үзенчәлекле сүзләр буларак, предметлыкны белдерәләр. Шуңа күрә исемгә хас булган предметлыкның грамматик мәгънәсе кушаматка да хас булырга тиеш. Язучы кушаматларында бу предметлык сан, килеш формаларында күренә. Каралган әдәби әсәрдәге кушаматлар, нигездә, ялгызлык һәм уртаклык исемнәренең конкрет һәм абстракт

җирлегендә барлыкка килгәннәр. Мәсәлән: Гармунчы Сирай, Лесник Талип Райком күсесе Әпчүк, Фауна, Төрмә кошы һ.б.ш. Сыйфат сүз төркемнәреннән ясалган кушаматлар алай ук күп очрамады: Аксак шайтан, Тискәре кәҗә һ.б.ш.

Күзәтүләр күрсәткәнчә, кушаматлар табигатьләре ягыннан күп төрле функция башкаралар. Ф.Садриев тарафыннан аларны куллануның төп үзенчәлеге шунда: кушаматлар сөйләүче һәм аталучы кеше арасындагы контакт булдыру функциясен үтиләр, шулай ук атаучының кушамат тагылган кешегә карата эмоциональ мөнәсәбәтен белдерәләр. Җыеп әйткәндә, характерлау, бәя бирү һәм сурәтләү функцияләрен үтиләр.

**Әдәбият**


1. Садриев Ф.М. Бәхетсезләр бәхете. Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 903 б.
2. Салахутдинова З.Ф. Лексико-стилистические особенности произведений татарского прозаика Вахита Имамова: Автореф. дисс. … канд. филол. наук. – Казань, 2010. – 30 с.
3. Саттар-Мулилле Г.Ф. Татар исемнәре ни сөйли? (Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге). – Казан: Раннур, 1998. – 488 б.



**Салимова Дания Абузаровна,**

*д. филол. н., профессор кафедры русского языка*
*и контрастивного языкознания,*
*Елабужский институт К(П)ФУ*
*г.Елабуга, Татарстан, Россия*
*e-mail: daniya.salimova@mail.ru*



УДК 81-11


# КАРЛ ФУКС КАК ЭТНОГРАФ-ТЮРКОЛОГ О САМОПРЕЗЕНТАЦИИ НАРОДОВ

# KARL FUCHS AS ETHNOGRAPHER, SPECIALIST IN TURKIC PHILOLOGY OF THE REPRESENTATION OF PEOPLES


*Статья выполнена в рамках гранта РГНФ проекта № 15-04-00011*



**Аннотация.** В статье речь идет о всемирно известной личности, о немце Карле Фуксе, который стал одним из первых ориенталистов, зарубежных этнографов, внесшим огромный вклад в татарскую науку. Карл Фукс как ученый-энциклопедист, как полиглот показал, как можно стать «своим» в совершенно чужой для него инокультурной среде и оставить на века добрую память о себе.



**Ключевые слова:** Карл Фукс, Казань, языки, этнограф, татары, нация.



**Abstract.** In the article speech goes about the world famous personalities, about the German Karl Fuchs, who was one of the first of Orientalists, foreign ethnographers who have made a huge contribution to the Tatar science. Karl Fuchs as a scientist-encyclopedist, as polyglot has shown how it is possible to become an insider in a completely foreign cultural environment and to leave on century good memory about yourself.



**Keywords:** Karl Fuchs, Kazan, languages, orientalist, member of the Tatar, nation.


В этом году в начале сентября исполнится 240 лет со дня рождения великого сына Германии и по-настоящему сыскавшего любовь у татар Карла Фукса. Об этом немце, сделавшем так много для российской науки и для татарского народа – в том числе, написано очень много. Только на материале двух известных книг К.Фукса «Краткая история города Казани» и «Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях», также опираясь на ряд публикаций, увидевших свет в связи с 230-летием со дня рождения ученого, попытаемся дать краткий экскурс в жизнь «Табиба Фукса». Его жизнь можно назвать образцовой в плане органичной интеграции личности в инокультурное государство.

Карл Фукс родился в Германии, в городе Герборне 6(18) сентября 1776 года, в семье, где образование и наука ценились выше всего. Отец Карла и его дед (Хофман) были уважаемыми профессорами, преподававшими в Высшей школе (университете) Герборна. Отец его занимался философией, а дед фармацией. Получил Карл Фукс высшее образование в Геттингенском университете, степень доктора медицины получил в Марбургском университете (к слову, в Марбурге учился Михайло Ломоносов). В 1800 году приехал в Россию, которую очень любил, считал своей Родиной и всю свою жизнь трудился на ее благо. Осенью 1805 года Карла Федоровича Фукса назначили профессором в только что открытый Казанский Императорский Университет. Обычно